КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 27 гыйнвар г.Казань № 25

2020 елга гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасының төп чаралары планын һәм 2020 елга Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы идарә органнарын, көчләрен әзерләү буенча оештыру-методик күрсәтмәләрне раслау турында

Татарстан Республикасы идарә органнары, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасы көчләренең әзерлек дәрәҗәсен алга таба күтәрү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгәннәрне расларга:

2020 елга гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасының төп чаралары планы (алга таба– План);

2020 елга Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы идарә органнарын, көчләрен әзерләү буенча оештыру-методик күрсәтмәләр.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына:

Планны үтәүне тәэмин итү буенча чаралар күрергә;

2020 елга гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә төп чаралар планын эшләү һәм гамәлгә кертү.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетларына тәкъдим итәргә:

Планны үтәүне тәэмин итү буенча чаралар күрергә;

билгеләнгән тәртиптә гражданнар оборонасы идарәсе органнарын һәм көчләрен, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү системасын һәм җирле дәрәҗәдәге гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системаны әзерләү буенча тиешле оештыру-методик күрсәтмәләрне, шулай ук 2020 елга Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының су объектларында кешеләр иминлеген һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендәге төп чаралар планын эшләргә һәм гамәлгә кертергә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасының төп чаралары планын һәм 2019 елга Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча идарә органнарын, көчләрен һәм территориаль ярдәмче системасын әзерләү буенча оештыру-методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2009 ел, 5 март, 154 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

5. Бу карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин